| СОВЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>«23»декабрь 2025 ел | **КАРАР**<br>№ 14 |

**Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгының, Урта Көшкәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 98нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 14 мартында 67 нче номерлы, 2024 елның 17 июле 100 нче номерлы, 2024 елның 30 нчы октябре 106нчы номерлы, 2025 елның 15 нче май 124нче номерлы үзгәрешләре белән)**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25енче ноябрь 994енче номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2025 елның 17енче декабре 26нчы номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба -

Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 25 декабрендәге 98 нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге советы карарына (14.03.2023. №67; 15.07.2024. №100; 30.10.2024. №106, 2025 елның 15нче май 124енче номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «21 091» санын “23 201» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар имза куйган көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Ю.М.Перфилов